# Чишмә башы

Арча икенче урта гомуми белем мәктәбе

махсус чыгарылыш

**Апрель**
**2025**

## Тукай яши безнең йөрәкләрдә

***Вакыт безне 1913 нче елның апрель көннәреннән ераклаштырган саен, Тукай безгә тагын да якыная...***

***Яздан аерып булмый Тукайны!***
***Язда килгән, язда ул янган.***
***Язы, киләчәге барлар ничек китсен,***
***Ничек югалалсын дөньядан.***

***Моннан 139 ел элек, 1886 нчы елның 26 нчы апрелендә дөньяга килеп, 112 ел элек, ягъни 1913 нче елның 3 нче апрель иртәсендә дөньядан китеп тә барган Тукай бүген дә безнең арабызда кебек. Аның иҗаты, аның геройлары безнең күңелләрдә, безнең җаныбызда.***

***Һәр язда халкыбыз бөек шагыйребезнең туган көнен билгеләп үтә. Һәр ел саен районыбызда, мәктәпләрдә сөекле шагыйребез иҗатына багышлап, әдәби кичәләр уздырыла. Иң зур бәйрәм - республикабыз башкаласы Казан шәһәрендә була. Ул күп меңләгән халык катнашында шигырь бәйрәме итеп үткәрелә.***

***Г. Тукай дөньяда бары тик 27 ел гына яшәгән, бары 8 ел гына иҗат иткән. Шулай булса да, ул гаять зур, бәя биреп бетермәслек рухи байлык калдырган. Аның тормышы һәм иҗаты - халкыбыз тарихында иң якты, иң изге сәхифәләрнең берсе. Балачактан күңелебезгә кергән Тукай безне гомеребез буена озата бара. Еллар үткән саен безгә якыная бара.***

### Кушлавыч

Бөдрә таллар үсә Кушлавычта
Көмеш сулы чишмә янында.
Тамырлары тирән, нык торалар,
Баш имиләр җилдә, давылда,
Ә кайвакыт ямансулый алар,
Ботаклары җиргә салына.
Хәтерлидер бәлки узганнарны,
Сагынадыр алар, сагына
Нәни Габдулланы. Сабый чакта
Ул бит шул талларга сыенган,
Ялан тәпи басып боз өстенә,
Авыз иткән чишмә суыннан.
Шушы җирдә яшәп, шушы җирдә
Туфрак булган җиде бабасы.
Бик еракта аның нәсел башы,
Биш гасырдан арта арасы.
Ирек сөйгән батыр халык салган
Кушлавычның нигез ташларын.
Төпләнгәннәр алар, качып килеп
Каһәреннән явыз патшаның.
Иген иккән халык гомер буе
Җирне ашлап ачы тир белән.
Уртак булган язмыш, авырлыкны
Күтәргәннәр алар ил белән.
Алгы сафка баскан ир-егетләр
Яу килгәндә Рәсәй өстенә.



Ватан өчен барган сугышлардан
Читтә калмаганнар берсе дә.
Кушлавычта изге һәр адым җир,
Кырларына куна торналар.
Бөдрә таллар Тукай суын эчкән
Чишмәләрне саклап торалар.
Чишмәләр күп монда, чишмәгә бай
Тукай туган авыл – Кушлавыч.
Күп гасырлы узган тарихы бар,
Киләчәге аның соклангыч...

***Әнәс Галиев,*** *Кушлавыч авылында туган фронтовик шагыйрь*

## Тукайның дүртенче буын туганы

Халык күңеленә үтеп кергән һәм тиз арада йөрәгеп яулаган шәхесләр бармак белән генә санарлык. Башка милләт шагыйрьләре белгән,яшь чагында ук олыларча үз-үзенә бәя бирә алган кеше русларда Пушкин булса,татарларда ул - Габдулла Тукай.

Габдулла Тукайның тормышын өйрәнү, туганнарын барлау күптәннән өйрәнелә икән. Хезмәтемне башкарганда мин Зәкия Рәсүлеваның “Тукай эзләреннән”дигән китабына тап булдым. Зәбировлар фамилиясенә тукталдым. Кем ягыннан, нәсел җепләре ничек Тукай белән тоташа икән дигән сорау белән укытучыма мөрәҗәгать иттем.

Арчада яшәүче Зәбиров Айрат абый белән очрашу үткәрелде. Алар бер гаилә икән! Айрат абый үзенең истәлекләрен сөйләде:

- Мин үземнең Тукай туганы икәнлегемне беләм. Минем әби — Мәсрүрә. Әбиемнең әнисе – Бибисаҗидә - Габдулланың әнисе Бибимәмдүдәнең ата бер, ана башка сеңлесе.

Мәсрүрә әби бик дингә бирелгән кеше иде, холкы бик тыныч, тыйнак. Без, өч малай, аның тәрбиясендә үстек. Авылның абыстае, аш-су остасы, тегүчесе... Әбинең сөйләгән сүзләре бүгендә хәтеремдә. Качырып кына ураза тотты, намаз укыды, дини китапларын кеше күрмәгәндә генә укыды. Бу китаплар бездә бүгендә саклана. Мин үземдә Тукай әкиятләрен укып үскән кеше,моның белән чиксез горурланам. Әтием Фоат (авыр туфрагы җиңел булсын) гомере буе колхозда алдынгы механизатор булды. Алар 4 бертуган: Суфия, Мәсгут, Әнисә һәм әтием Фоат.

“Үзеңнең җиде буыныңны белергә кирәк”,- дигән гыйбарә яши безнең халыкта. Бөек Тукаебызның дүртенче буын туганы белән якыннан танышу һәм аралаша алуым белән горурландым. Тукай туганнары белән очрашуларны республикакүләмендә оештырырга кирәктер. Без үткәнебезне кадерләп сакларга, киләчәк буынга җиткерергә бурычлыбыз.

***Алинә** Бәдриева, 8В сыйныф укучысы*

# Габдулла Тукай — милләтемнең рухи юлбашчысы



Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.
Шул халыкныңмы хокукка хакгы юк? —
Хаклыбыз уртак ватанда шактый ук!

*Г.Тукай*

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның күренекле шәхес икәнлеге турында уйланганда, мин иң элек, нәкъ менә татар милләте, татар халкы өчен эшләгән эшләре, язган шигырьләрен әйтергә телим. Шагыйрь үз туган илебез киләчәген кайгыртып, башкаларның да шәм-лампа кебек үз тирәсен генә яктыртырга тиеш түгеллеген әйтә. Шагыйрь өчен милләткә бәйле булган сораулардан да зуррак, мөһимрәк нәрсә була алмаган. Көндәлек тормыш тудырган мәсьәләләр дә алар янында бик вак булып калганнар. «Үз-үземә» шигыреннән алынган юллар язганнарымны тагын да ныгыта:

Күңел берлән сөям бәхтен татарның,
Күрергә шаһлыгын, тәхтен татарның.
Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

Бу шигырь юллары аның туган милләтебезгә булган мөнәсәбәтен дәлилләп тора. Тукай халкыбыз рухында мәңге яшәячәк, чөнки халык рухы аның әсәрләренә бик тирәнтен кереп урнашкан. Әнә бит “Әллүки”, “Тәфтиләү”, “Зиләйлүк”, “Туган тел” кебек җырлары шулкадәр халыклашты, аларны нәкъ менә Тукай иҗат иткәне сизелми дә. “Туган тел”е аеруча еш яңгырый. Күп кенә әдәби кичәләр, хәтта төрле җыеннар да шушы җыр яңгыравы белән тәмамлана. Халкыбыз гимнына әверелгән “Туган тел”не барлык илләрдә яшәүче татар баласы укый һәм көйли.

Белгәнебезчә, Г. Тукай – милли шагыйрь. Халкыбызның гореф-гадәтләрен, бәйрәмнәрен, бай телен, сәнгатен чын күңелдән яраткан башка шагыйрь бармы икән тагын? Ул бары милләтем, халкым дип эшләгән һәм яшәгән. Кечкенәдән татар халкының ачы язмышын күреп, газапларын үз җилкәсендә тоеп үскәнгәдер, халкыбыз тормышын, проблемаларын шигырьләренә тирәнтен яшергән. Шуңа күрә дә иҗатын туган халкына хезмәт итүгә багышлаган.

Минемчә, шагыйрьнең “Фикер” гәҗитендә (1906 ел) басылган бер мәкаләсендә халкыбызны иң борчыган мәсьәләләрнең берсе - татарларда укыту системасының артталыгы турындагы язманы мисалга китереп тә, аның никадәр халыкчан шагыйрь икәнен дәлилләп булыр иде. Бу язмада ул милли мәгариф язмышы темасын күтәреп кенә калмый, аны алга җибәрү юлларын эзли.

Халык арасында дан казанган, татар халкының тормышын, язмышын үзенең шигырьләренә шулай тирәнтен яшерүе, иң беренче чиратта, аның каян килеп чыкканына бәйледер. Кечкенә Апуш булып, сабый чагыннан ук ятимлектә, өйдән-өйгә күчеп йөреп яшәгән, кечкенәдән татар халкының ачы язмышын күреп, газапларын үз җилкәндә, үз тәнендә татып үскән шагыйрь иң түбәннән өскә үрмәләп, бөек Тукай булган. Ни генә булмасын, сабыйлыкта үз канаты астына аны халкым сыендырган. Аннан яклау да, саклау да тапкан шагыйрьнең иҗатында халкым тормышы бөтен тулылыгы белән ачыла. Үзенең бөтен иҗади көчен туган халкыбызга хезмәт итүгә, аны милләт буларак аклауга һәм үстерүгә багышлаган Бөек Тукай - безнең татар әдәбиятына салынган таза, ныклы нигезебез.

Дымлы апрель җиле исә. Тукай шул җилләргә кушылып нидер әйтә кебек... Бик күп мәктәп, аудиторияләрдә, театр сәхнәләрендә, мәданият сарайларында, клубларда, радиоларда өзлексез яңгырап, безнең уй-тойгыларыбызны яңартып, яшәүгә, хезмәткә, иҗатка илһамландыра. Әнә шулай безне көрәшкә чакыра Тукаебыз!

***Мәликә*** *Җәләева, 9 А сыйныфы укучысы*

# Тукай — дөнья картасында

***Тукай исеме белән аталган обьектлар арасында Арча үзәгендә, тимер юл станциясендә бюст, Шәрык янындагы мәчет мәйданы, рухи - мәгърифәт үзәге, Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте, Арча станциясендәге урам, Кушлавыч, Яңа Кырлай авылында музей, "Казан арты" тарих-этнография, әдәбият-сәнгать музеенда экспонатлар бар.***





***Редактор*** татар теле һәм әдәбияты укытучысы Ибраева Р.Х.

***Дизайнер - верстальщик*** Гүзәлия Фәттахова

***Фотокорреспондент*** Рулан Коморов

***Корректор*** Эльмира Забирова

***Редколлегия*** Мәликә Җәләева

Алинә Бәдриева

***Адрес:*** Күпер урамы, 15 нче йорт.

***Мәктәп сайты:*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2